



ӨЧ КЫЗ



ӨЧ КЫЗ

(ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕ)

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1959



Редакторы
К. Котдусова

Художнигы
Л. Муллинова



МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАР ӨЧЕН



ӨЧ КЫЗ


(ТАТАР ХАЛЫК ӘКИЯТЕ)

ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
Казан 1959



Борын-борын заманда булган икән, ди, бер хатын. Аның булган, ди, өч кызы. Бу хатын, кызларымның өсте бөтен, тамаклары тук булсын, ди-ди, көне-төне эшләгән, ди.

Менә кызлар буйга да җиткәннәр. Алар берсеннән-берсе матур, ди, бер битләре ай,



бер битләре кояш, буй-сыннары карлыгачтай сылу, ди. Өч кыз туган, бер-бер артлы кияүгә чыгып, берсе артыннан берсе китеп тә барганнар.

Менә бер ел үткән, ике ел, өч ел үткән. Шулай матур гына яшәгәндә, әниләре авырып киткән. Күрше урманда тиен-дусты бар икән, шуны дәшеп әйткән:

— Тиен-дустым, барсана, кызларыма әйтсәнә, хәлемне белергә килсеннәрче, — дигән.





Тиен шунда ук чыгып чапкан. Тиен барып тәрәзә какканда, олы кыз җиз ләгәннәр чистартып торадыр иде, ди.


— Һай, — дип әйткән, ди, олы кыз, — бик барыр идем дә бит, аңарчы менә шушы ләгәннәрне чистартып бетерәсем бар иде шул, — дигән, ди.


Тиен моңар бик ачуланган да әйткән:

— Алайса син шушы ләгәннәреңнән мәңгегә аерылма! — дигән.

Тиеннең шулай дип әйтүе булган, ике ләгән кызны ике яктан китереп тә кысканнар. Олы кыз егылган да шунда ук гөберле бакага әверелгән.

Тиен уртанчы кызга чыгып чапкан. Ур-





танчы кыз бу кайгылы хәбәрне ишеткәндә, киндер суга икән. Тиенгә әйткән:

— Һай, — дигән, — әнием янына хәзер үк чыгып йөгерер идем дә бит, менә ярминкәгә киндер сугып өлгертәсем бар иде шул, — дигән.

Тиен бик ачуланган да әйткән:

— Алайса син гомерең буе киндер сугып кына тор! — дигән.

Уртанчы кыз шунда ук үрмәкүчкә әверелгән.



Тиен тәрәзәсен како кканда, кече кызның камыр баскан чагы икән. Ул бер сүз дә әйтмәгән, камырлы кулларын да сөртеп тормаган, чыккан да әнисе янына йөгергән.

Тиен кече кызга әйткән:

— И сөекле бала, — дигән, — гомер буе игелек күр, кешеләрне бәхетле ит, аларга куаныч та, юаныч та бул. Кешеләр дә сине сөярләр, синең яхшылыгыңны мәңге онытмаслар, — дигән.

Кече кыз чыннан да бик рәхәт гомер кичергән, халык аны бик яраткан, ди.





ТРИ ДЕВУШКИ

(на татарском языке)

Художество редакторы *Э. Е. Дьячкова*
Техник редакторы *Р. С. Нәбиуллина*
Корректоры *Р. С. Хамидуллина*

Производствога бирелде 22|V-58 ел. Басарга кул куелды 9|I-59 ел. Кәгазь форматы 70x92'|16.
Учетн.-изд. 1,04 табак. Басма табак 1,0(1,17). Табакта 33944 знак. Заказ № А-246. Тираж 19000 экз.
Бәясе 75 тиен.

Татарстан Культура министрлыгы каршындагы нәшрият һәм полиграфия промышленносте бүлегенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19, 1959 ел.

Бәясе 75 тиен.





ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1959